**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БОЛЬШЕЕЛГИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422640, с. Большая Елга,
ул. Октябрьская, дом 25

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ ЕЛГА АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422640, Олы Елга,
Октябрь урамы, 25 нче йорт

Тел.: (84361) 25265, факс: (84361) 25265, e-mail:Belg.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**16 март 2020 ел** **Олы Елга ав.** **№ 3**

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Олы Елга авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының 2004 елның 24 мартындагы “Җирле референдум турында” 23-ТРЗ номерлы Законы,Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Олы Елга авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, 2020 елның 31 октяберендә Узган Олы Елга, Казаклар авылы гражданнар җыенында кабул ителгән 1 номерлы, 2020 елның 31 октябрендә узган Саеска Тавы, Кама поселогы авылы гражданнар җыенында кабул ителгән 1 номерлы карарларын тормышка ашыру максатында КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсемуниципаль районы “Олы Елга авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыюның кушымта итеп бирелә торган Тәртибен расларга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Олы Елга авылы , Октябрь урамы, 25 нче йорт; Казаклар авылы, Үзәк урам, 9 нчы йорт; Саескан Тавы авылы, Үзәк урам, 16А йорт; Кама поселогы, Курортная-2 урамы, 23 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмати-

телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3.Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Башкарма комитетының баш бухгалтеры Шарафеева Миләүшә Илдус кызына йөкләргә.

Балык Бистәсемуниципаль районы
Олы Елга авыл җирлеге
Башлыгы Ф.Ә.Садриев

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Олы Елга авыл җирлеге
Башкарма комитетының 2020 елның
16 мартындагы
3 номерлы карары
белән расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Олы Елга авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю Тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Олы Елга авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү Татарстан Республикасы Балык Бистәсемуниципаль районы “Олы Елга авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан (белем алуның көндезге формасында укучы студентлардан гайре, аларның саны җирлектә яшәүчеләрнең гомуми санының 30 процентыннан артык була алмый)җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашуларына һәм тавыш биргәндә алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләргә бәйсез рәвештә 2020 елның 31 мартына кадәр башкарыла.

3. Бер тапкыр түләү турында хәбәрнамә бланкы (әлеге Тәртипкә кушымта) гражданнар игътибарына Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәгеhttp://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда игълан итүһәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру (халыкка белдерү) ысулы белән, шулай ук кул куйдырып тапшыру юлы белән яисә почта аша юллап җиткерелә.

Хәбәрнамәдә гражданнарның үзара салым акчасын күчерү реквизитлары, тулы яисә киметелгән күләмдә бер тапкыр түләнә торган түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

4. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Олы Елга авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең лицевой счетына керә.

5. Гражданнар тарафыннан түләүләр акча средстволарын физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясау хокукына ия булган, почта переводларын (исәп-хисап оешмалары) гамәлгә ашыру хокукына ия булган оешмалар аша, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Башкарма комитеты кассасы аркылы яки https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенчаТатарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша күчерү юлы белән башкарыла.

6. Түләү фактын раслаучы булып керем (приход) касса ордерының тамганамәсе, чек-ордер, түләү фактын раслаучы башка документлар тора.

7. Гражданнарның билгеләнгән срокта кертелмәгән үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
“Олы Елга авыл җирлеге”
муниципаль берәмлеге территориясендә
гражданнарның үзара салым акчаларын
җыю Тәртибенә КУШЫМТА

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсемуниципаль районы “Олы Елга авыл җирлеге”
Муниципаль берәмлеге бюджетынаүзара салым буенча
бер тапкыр түләнелә торган түләүне түләү турында
ХӘБӘРНАМӘ №_________

ТүләүченеңФ.И.А.и. _______________________________________________________________
Адрес: ________________________________________________________________
_______________________________________________________________________нигезендә
Сезгә 2020 елның 31 мартына кадәр_________________________________________
________________________________чараларын тормышка ашыруга бер тапкыр түләнелә торган ________сумма күләмендәге түләүне түбәндәге реквизитлар буенча түләргә кирәк: ___________________________________________________________
БИК (банкның таныклаучы коды) алучы банк
_______________________________________
Сч. № ___________________________________
Сч. № алучы__________________________________________
ИНН ___________________________________________
КПП ___________________________________________
КБК _______________ ОКАТО __________________
Түләүнең билгеләнеше
_____________________________________________________________________________

Җитәкче _________________ __________________________________________
М.У. (имза) (имзаның расшифровкасы)

- - - - - - - - - - - - - - - - - **кисү сызыгы** - - - - - - - - - - - - - -

Татарстан РеспубликасыБалык Бистәсемуниципаль районы “_____________ авыл (шәһәр) җирлеге”муниципальберәмлегебюджетынаүзарасалымбуенчабертапкыртүләнеләторган _________________сум күләмендәгетүләүнетүләүтурындаХӘБӘРНАМӘ №_________
Түләүченең Ф.И.А.и. ____________________________________________________
Адрес:______________________________________________________________________
Алдым “____”_______________, 20__ ел
____________________________________________
(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Хәбәрнамә түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта ертып алына торган төпсә тутырыла һәм _______________җирлеге Башкарма комитетында кала.*